МАОУ СОШ №4

# Наше Время!

# Безнен Вакыт!

СЕНТЯБРЬ—ОКТЯБРЬ



**Бөтендөнья укытучылар көне**

**Укытучыма әйтер сүзем**

**Укытучыма шигырьләр**



**Матур буласың килсә...**

Все интервью с учителями в специальном выпуске газеты






**Бөтендөнья укытучылар көне ЮНЕСКО тарафыннан 1994 елда билгеләнеп үтә башлый. 5 октябрь көнне бәйрәм ителә. Бөтендөнья укытучылар көне БМО бөтендөнья һәм халыкара көннәре исемлегенә керә. Бу көн укытучылар-ның җәмгыять эчендәге хәленә, аларның мәгарифтә һәм алга китештә алып торган урынына игътибарны җәлеп итәр өчен үткәрелә. Бөтендөнья укытучылар көнен 100дән артык дәүләт бәйрәм итә, кайчак аерым милли Укытучы-лар көне бәйрәм ителә.**



МАОУ "СОШ №4"









## Слова благодарности учителям

Каждый человек когда-то расстается со школой. Но в памяти навсегда останутся незабываемые школьные дни. Уроки с большой буквы, на которых мы изучали не только необходимый материал, но и постигали нечто большее.

Сказать благодарственное слово учителю – это всегда сложно, потому что трудно подобрать достойные слова, которые могут выразить всю глубину искреннего признания и уважения к людям, посвятившим свою жизнь школе, открывающим для нас мир знаний. Хотелось бы сказать слова благодарности нашим учителям за их терпение и труд, за постоянное стремление сеять доброе, мудрое, вечное.

Педагогам сегодня – мои поздравления!
Здоровья вам, счастья и радостных дней,
Успехов в работе, а в жизни – везения,
И самых воспитанных, добрых детей!
Пусть все удается в трудах да заботах
И сложится к лучшему ваша судьба,
Ведь нет благородней, почетней работы,
Чем счастьем наполнить ребячьи сердца!
Стараетесь школу теплом обустроить,
Ребятам домашний уют подарить.
А это, друзья, дорогого то стоит,
Детей научить, воспитать, полюбить!
Спасибо, родные, за труд неустанный,
За сердце большое и щедрость души,
В своей доброте будьте вы постоянны
Судьба вас одарит – исполнит мечты!

Выпуск 2002 г. Хайдарова-Абдуллина Лилия

2015 г.

# Бәйрәм белән!



Безнең Вакыт! Наше Время!


















# Бәйрәм белән!



















Өйрәттең хәреф танырга,
Сүзләр төзеп укырга.
Сабырлык белән өйрәттең
Санга санны кушарга.

Алып кердең безне шулай
Серле гыйлем иленә.
Без ул фәннәр дөньясында
Очратмадык ни генә!

Шаулы мәктәп елларыбыз
Үтте дә китте очып,
Ә Сез һаман истә әле,
Беренче укытучым!

# Укытучыма әйтер сүзем ...



Сезне Укытучылар көне белән тәбрик итәбез. Сезгә бәхет, саулык, байлык һәм озын гомер телибез. Сез бик матур, изге күңелле һәм балалар яратучы укытучы. Без сезне бик яратабыз! 6Б сыйныф

Минем бик яраткан укытучым бар! Беренче тапкыр күргәч, мин уйладым ул бик усал диеп, ә хәзер бик-бик яхшы икәнен аңладым. Алсу Фавизовна тарих дәресен укыта. Мин дәрестә әйбәт утырам, дәрестә сөйләшергә тотынсак, апа безне әз генә орышкалый башлый. Миңа тарих дәресе һәм Алсу Фавизовна да ошый!




Мингалимова Гүзәл

МАОУ "СОШ №4"





**И, сөекле укытучым,**
**Син һәрвакыт исемдә!**
**Беркайчан да тап төшермәм**
**Синең горур исемгә!**

**Рәхмәт, Сезгә чын күңелдән,**
**Рәхмәт барысы өчен!**
**Мин бәхетләр телим Сезгә,**
**Беренче укытучым!**









**НАШЕ ВРЕМЯ! БЕЗНЕҢ ВАКЫТ!**

**Безнең 4 нче мәктәптә укытучыларны сайлап алган кебек. Алар шундый яхшы, ярдәмчел, үз эшләренә тугры. Барысы да мактауга лаеклы. 5нче сыйныфка килгәндә безне көләч, якты йөзе белән Ольга Сагатовна каршылады. Ул тыныч, ягымлы һәм сабыр. Аның дәресләре бик кызыклы. Мавыктыргыч. Безнең өчен борчыла, кирәк вакытта ачулана да белә. Математика фәнен  шат күңелле Эльвира Тагировна өйрәтә. Татар телебездә дөрес сөйләшергә, әдәби әсәрләр, язучылар белән безне мөлаем Ландыш Сахаповна таныштыра. Фәнүзә Махасимовна безгә рус теле һәм әдәбият дәресләрен укыта. Ул үз эшенең чын остасы. Тагын безнең яраткан укытучыларыбыз: чит телләрдән Сария Хамисовна, физкультура укытучысы Николай Иванович, тарих һәм җәмгыять белеменнән Фәридә Бахтияровна, җыр һәм музыка укытучысы Илһамия Гилемхановна. һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан аларны тәбрик итәм. Аларга сәламәтлек, зур уңышлар, сабырлык телим!**

**Гайнимохәмәтова Илүзә 7А**



# Бәйрәм белән!



**Безнең яраткан укытучыбыз—Ландыш Сахаповна. Дәресләре бик күнелле темпта уза. Темаларны гади аңлаешлы итеп аңлата. Дәресләрнең узганын сизми дә калабыз. Ул матур. Ягымлы, һәр вакытта да ачык йөзле һәм сөйкемле. Укытучы апаларның хезмәте бик авыр һәм катлаулы. Без үзебезнең  укытучы апаларыбызны яратырга, хөрмәт итәргә тиеш.  Ландыш Сахаповнага эшендә унышлар, гаилә бәхете һәм сәламәтлек телибез. Гел шулай яшь, матур булып калыгыз! Ландыш Сахаповна— безнең  генә түгел, барлык балаларның да яраткан укытучысы.**

**Храмова Регина, Файзиева Чулпан 6Б сыйныфы**



**Укытучыма әйтер сүзем …**

**Укытучы ул шундый кеше, авыр әйберләрне дә җиңел итеп бирә ала. Укытучы булу бик авыр, җаваплы эш. Һәр-бер кеше укытучы була алмый. Кем соң ул чын укытучы? Аның исеме Растегаева Гүзәл Дәүләтгәрәй кызы.**

**Ул рус теле һәм әдәбиятыннан дәрес бирә.**

**Укытучылар көнендә бик күп җылы сүзләр яңгырый. Һичшиксез, укытучылар бу сүзләрне һәркөн ишетергә ти-еш, бу бәйрәмнән башка. Кадерле Укытучыбыз, сез-безнең мәктәпнең йөрәге, укучыларның терәге!**

**Салихова Ләйлә 10А**

**Интервью башлангыч сыйныф укытучысы Халимова Нәфисә Язкаровнадан алынды. 8В сыйныф укучылары: Нургалиева И., Ганиева Э., Ахмадиева А., Захарова А.**



- **Минем өчен «укытучы» - ул балаларны чын күңелдән ярата белүче; эшенә теләк белән килүче; үзе укыткан укучыларының уңышларын күреп, сөенә белүче.**
- **- Кечкенәдән аерып «кемдер» булырга хыялланмадым. Өлкән сыйныфларда укыганда «физкультура» укытучысы буласы килү теләге туды. Ә башлангыч сыйныф укытучысы ул—универсал кеше. Үзеңне төрле яктан үстереп була.**
- **- Яшь олыгайган саен укучыларның йогынтысы сизелә. Быелгы уку елына, 31 бала арасына куркыбрак килгән идем. Бик тиз ияләштем.**
- **- Гомуми эш стажым 36 ел. Педагогик стажым быел 25 ел була, бу мәктәптә 22 ел.**

**- Минем карашка—хәзрге балаларда укуга омтылыш та, китаплар укуга теләк тә, укытучы-ларга хөрмәт тә түбән дәрәҗәдә. Хәзерге яшьләр ваытларын юкка үткәрәләр, белемне җиңел юл белән (заманча техникаларга таянып) табуны кулай күрәләр. Мин үзем мәктәптә укыган-да коммерческий институтлар юк иде. Институтка үз көчең, белемең белән керү, уку—үзе бер дәрәҗә саналды.**



**Мин аны яратам, чөнки беренчедән аның фәне. икенчедән ул бик яхшы аңлата. Эль-вира Тагировна бик әйбәт укытучы. Гадел, түземле һәм тыныч. Безне ярата, безнең әйбәт укуыбызны тели. Безнең уңышларга сөенә. Начар билгеләребезгә борчыла. Дәресләрен бик кызык итеп үткәрә. Аңла-маган темаларны кат-кат вакытын кызган-мыйча аңлата. Үз фәне буенча барлык со-рауларга да җавап таба. Менә шундый оста укытучы ул.**

**Каюмова Альбина 7А**



# Укытучыма шигырьләр

## Укытучыма

Укытучым! Бөек илаһи зат,
Әниләрдәй якын кешебез.
Белем бирү өчен тырышасыз,
Биреп безгә бөтен көчегез.
Түземлекне, акыл, сабырлыкны
Биргән Ходай сездәй затларга.
Үзегезнекедәй күреп,якын итеп,
Эндәшәсез һәрбер балага.
Үрнәк булып, туры юл күрсәтеп,
Начарлыктан безне яклыйсыз.
Акыллы һәм төпле киңәш биреп,
Ялгышлардан безне саклыйсыз.
Укытучы апам! Мин хөрмәтләп
Сезгә шулай диеп эндәшәм.
Кирәк чакта Сездән ярдәм сорыйм,
Серләремне сөйләп, киңәшәм.
Үзегез дә, кылган эшегез дә –
Барысы да якын күңелгә.
Сезгә булган хөрмәт арта бара
Рәхмәтлебез Сезгә гомергә.
Һич ялгышмам:”Укытучы”сүзен
Кояш белән әгәр тиңләсәм.
Шушы олы хезмәт иясенә
Куяр идем һәйкәл мәрмәрдән.
Сабирова Миләүша 9Всыйныф






## Мәктәбемне яратам.

Мәктәбемне бик яратам.
Укытучы апамны.
Яхшы укырга тырышам,
Яратам мактаганны.
Дәресләрдә бик теләп,
Укыйбыз да, язабыз.
Сөйлибез дә, уйлыйбыз да,
Бик күп белем алабыз.
Загитов Таһир, 5 а сыйныфы укучысы.

## Мәктәптә.

Тәртип һәм уку рәвешен
Без бәяләп барабыз.
Гел беренче булырбыз без,
Һич тә артта калмабыз.
Матур көннәр булганда,
Походларга чыгабыз.
Туган жирне күзәтәбез,
Рухи азык жыябыз.
Гыйлметдинов Камил, 5 а сыйныфы укучысы.

# Укытучыма шигырьләр

**Укытучы буласым килә.**

**Күз җиткәчтен, шатланышып,**
**Без мәктәпкә барабыз.**
**Һәр көн саен җыелышып,**
**Анда белем алабыз.**
**Бергәләшеп, сөенешеп,**
**Шау-гөр килеп яшибез.**
**Укытучы апаны да**
**Бик яратабыз шул без.**
**Укытучы килеп кергәч,**
**Сыйныф яктырып китә.**
**Вакыт үткәнен сизмибез,**
**Дәресләр дә тиз үтә.**
**Безнең сөекле апабыз**
**Бар нәрсәне дә белә.**
**Аның кебек укытучы**
**Үскәч буласым килә.**

**Хакова Алина 9В сыйныф**







**Мәктәптә.**

**Мин мәктәпне яратам,**
**Көн дә ашкынып барам.**
**Бишлеләрне күп алып,**
**Дәрестән кайтам арып.**

**Галимов Разил, 5 а сыйныфы укучысы.**



МАОУ "СОШ №4"

# Матур буласың килсә ...



Чәчне карый беләбезме? Берәүләр аның ние бар, шампунь саласың да юасың, диләр. Ә чынлыкта исә чәчне дөрес юмау баш тиресе ялкынсынуына, чәч коелуга, юкаруына китерә. Нормаль чәч шома, ялтырап торучан. Аның очлары икегә аерылмый, чәч 4-5 көннән соң майлана. Нормаль чәчнең кышын баш киеменнән йөргәнгә, тизрәк үз формасын югалтуы да мәгълүм. Шуңа чәчем тиз майлана башлады дип артык хафаланмагыз. Майлану ел фасылына, майлы ризык куллана башлауга дабәйле. Коры чәч ялтырамый, икегә аерыла. Аны бер атна юмасаң да, майлы кебек күренми. Майлы чәчне аеру авыр түгел. Ул иртән юылса, кичкә үк майланып ката. Шампуньны сайладык. Ә хәзер башны юа торган суны хәстәрлик. «Ник, краннан агып торган су ярамыймы инде?» - дияр берәүләр. Юк шул, чәч суны тирегә караганда да яхшырак сеңдерә. Су белән аңа хлорлы суда була торган начар матдәләр дә керә. Элек исә хатын-кызлар яңгыр суыннан файдаланган. Бүген санитария белгечләре моны киңәш итмәс иде. Шуңа үз сәламәтлеге, матурлыгы кадерле булган гүзәл зат «яхшы» суны үзе ясый ала. Моның өчен кайнаган суның 1 литрына 1 чәй калагы исәбе белән сода салырга кирәк. Ә инде чәчне тәрбияләүнең «алтын кагыйдәләре»н белү беркемгә дә зыянга булмас дип уйлыйм.



▪ Чәчне юар алдыннан йомшак трарак белән тарарга;
▪ Чәч юыла торган су сезнең өчен уңайлы булырга тиеш. Гадәттән тыш кайнар су май бизләре эшчәнлеген көчәйтеп, чәчнең тизрәк майлануына китерә. Шуңа чәче тиз майлана торган хатын-кызларга салкынчарак су кулланырга да ярый; ▪ Шампуньне кулда су белән күпертеп, аны башка тигез итеп сыларга; ▪ Чәчне тырнак белән түгел, ә бармак очлары белән массажлап юарга кирәк; ▪ Маңгай-чигә тирәсен дә шампуньләп юарга онытмагыз — алар да пычрана бит; ▪ Шампуньне берьюлы күп итеп салганчы, ике тапкыр әз-әзләп сөртеп юу отышлырак булыр, чөнки күп салынса, ул еш кына агып кына төшеп әрәм генә була; ▪ Аннан соң чәчкә кондиционер сөртеп, аны бармак очлары белән җиңелчә массажларга киңәш ителә;



▪ Чәчне фен белән бик ашыгыч булганда гына киптерергә кирәк, ә башка очракта аның бүлмә температурасында кибүе хәерле;
▪ Чәчне кипкәч тарарга тырышыгыз.

## Данлыклы укытучым.

**Гасырлардан гасырларга**
**Данлы син, укытучым.**
**Мәңге-мәңге яшә җирдә**
**Данлыклы укытучым.**
**Ераклардан тора балкып**
**Нурлылык сезнең йөздә.**
**Шул сабырлык һәм ярату**
**Ул сезнең күңелегездә.**
**Сездәге шушы сыйфатларны**
**Без алабыз күңел түренә.**
**Дөрес итеп аны кулланырбыз**
**Тормыш юлын атлап үткәндә.**

**Хашитова Ләйлә 9В сфйныф**







## Әнием-укытучым.

**Чибәр түгел, әмма бик сөйкемле,
Нурлы йөзле, сихри карашы.
Күпме кеше сиңа гашыйк икән,
Киң күңелле укытучым минем,
Укытучы минем – минем әнием.
Балаларга белем таратасың,
Ихтирамлы, назлы карашың.
Барыбызга тәмле сүзең житә,
Игътибарлы укытучым минем,
Укытучым минем – минем әнием.
Һәр баланы якын, тигез күреп,
Белем таратасың уфтанмый.
Сәламәтлек белән озак яшә әле,
Мәрхәмәтле укытучым минем,
Укытучым минем – минем әнием!**

**Талипова Регина 5А сыйныф**








**Два года назад, Салават Анасович пришел в нашу школу. Но, думаю все со мной согласятся, стал для всех нас родным. Помимо того, что он хорошо обучает своему предмету, он умеет общаться с учениками. (Ученики 11А класса)**



- **Что для Вас значит быть учителем?**
- **- Это очень важно для меня, ведь я передаю свои знания будущему поколению и от меня зависит знание предмета—информатика. Моя учительница всегда была для меня примером. Профессия учителя сама меня выбрала—на четвертом курсе, после практики. Я сидел на паре и думал:-что мне делать дальше? Где работать? И тут заходит наш декан с директорм школы, который искал учителя информатики. Я подмал, что это судьба. Так я и оказался в школе. У меня всегда была склонность к информатике и математике. Свом коллегам желаю—терпения. Это очень важно в нашей профессии.**






**В настоящее время эпидемиологическая ситуация по гриппу и острым респираторным вирусным инфекциям в РФ остается напряженной. Грипп – острое инфекционное заболевание дыхательных путей, вызываемое вирусом гриппа, входящее в группу ОРВИ. По частоте и количеству заболеваний грипп и ОРВИ занимают первое место в мире, составляя 95% всех инфекционных заболеваний. Смертность от гриппа остается высокой, ежегодно в мире от гриппа умирают 2 миллиона человек. На данный момент одним из эффективных методов профилактики заболеваний и тяжелых осложнений гриппа остается вакцинация. Вакцинация предлагает наиболее логичный путь защиты от гриппа, учитывая серьезный характер заболевания, его широкое распространение, высокие показатели ежегодной заболеваемости, высокую смертность и заболеваемость среди лиц из группы высокого риска, а также ограниченные возможности лекарственной терапии. Вакцинация помогает предотвратить заболеваемость гриппом, сократить количество случаев госпитализации и смертельных исходов в результате осложнений, связанных с гриппом.**








**Массовая иммунопрофилактика населения против гриппа проводится с сентября по 20 ноября 2015 года вакциной «Гриппол». Вакцина формирует стойкий специфический иммунитет против гриппа. После вакцинации антитела появляются через 8-12 дней, иммунитет сохраняется до 12 месяцев. Вакцины против гриппа показали себя очень эффективным и хорошо переносимым средством у здоровых и лиц из группы высокого риска. Имеющийся опыт применения инактивированнных гриппозных вакцин характеризуется, в подавляющем большинстве случаев, очень хорошей переносимостью. Жесткие требования, многолетний опыт производства, отлаженные технологи – гарантия безопасности этих препаратов. На протяжении последних десятилетий ежегодно применяются десятки миллионов доз гриппозных вакцин.**

**В целях предотвращения и снижения ущерба здоровья населения от заболевания гриппом и ОРВИ в эпидсезоне 2015 гг. в рамках приоритетного национального проекта «Здоровье», все подлежат обязательной вакцинации против гриппа.**

# Осенний урожай















**НАШЕ ВРЕМЯ! БЕЗНЕҢ ВАКЫТ! Главный редактор—Власова М.Д. корреспондент газеты:Салихова Л..**